Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«19» ноябрь 2022 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыенында каралуга чыгарылган мәсьәләгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: слова «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зүзәй авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәләнгеш елгасы аша күперне реконструкцияләү, шул исәптән техник документация әзерләү» сүзләрен: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Зүзәй авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәләнгеш елгасы аша күперне реконструкцияләү, шул исәптән техник документация әзерләү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Зүзәй авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәләнгеш елгасы аша күперне реконструкцияләү, шул исәптән техник документация әзерләү.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.Н. Пинин
Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин